**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2022 елның 15 июле 1686 номер

# КАРАР

## Газүткәргеч урнаштыру максатыннан 16:24:260201:3064 кадастр номеры белән җир кишәрлеге чикләрендә территорияне межалау проектын әзерләү турында.

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Газүткәргеч урнаштыру максатыннан 16:24:260201:3064 кадастр номеры белән җир кишәрлеге чикләрендә территорияне межалау проектын әзерләүгә керешергә.
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 статьясы нигезендә билгеләргә.
3. Ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2022 елның декабренә кадәр билгеләргә.
4. Физик һәм юридик затларга әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне межалау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә..
5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.А. Новиков**